Информацион хат №1

**Казан (Идел буе) федераль университеты Халыкара мөнәсәбәтләр,тарих һәм көнчыгышны өйрәнү институты**

**Н.И.Лобачевский исемендәге Фәнни китапханә**

**Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе**

**Ш.Мәрҗани исемендәге тарих институты**

**Россия тарих җәмгыяте**

**Россия көнчыгышны өйрәнүчеләр җәмгыяте**

**Татар телен һәм мәдәниятен саклау һәм өйрәнү җәмгыяте “Җыен”**

2014 елның 27-29 маенда КДУ профессоры, ТР ФА академигы М.Г. Госмановның (1934-2010) 80 еллыгына багышланган халыкара фәнни конференция уздыра һәм сезне конференциядә катнашырга чакыра.

## Төрки-мөселман дөнья: бердәмлек, мирас һәм өйрәнү перспективалары

- Конференция эше түбәндәге секцияләр (юнәлешләр) буенча узачак:
- Алтын Урда һәм аның мирасы
- Төрки-татар цивилизациясе
- Тарихта шәхес
- Шәрекъ чыганакчылыгы мәсьәләләре
- Россидә шәрекъ археографиясе
- Китап традициясе һәм татар әдәбияты
- Татар дини фикере һәм Россиядә мөселман дини институтлары
- Мәдәни мирас һәм татар халкының милли-мәдәни үзәкләре

Конференция пленар һәм секцион утырышлар,түгәрәк өстәл рәвешендә уздырылачак. Конференциядә катнашу өчен 31 мартка кадәр доклад яки чыгыш темасы,автор турында белешмә (Ф.И.О., гыйльми дәрәҗә, исем, вазыйфа, эш урыны;адрес,телефон;e-mail) белән заявка җибәрүегезне сорыйбыз. Заявкага аерым файл белән докладның тезисларын (2 биттән дә артык түгел) теркәү мәҗбүри. Оештыру комитеты докладларны сайлау хокукына ия. Докладлар саны чикләнәчәк. Докладларны сайлау нәтиҗәләре һәм чыгымнарны финанслау мөмкинлеге 2014 елның 14 апреленә кадәр хәбәр ителәчәк. Заявкаларны җаваплы сәркатип профессор Д.М.Усманова (e-mail:dusmanova2000@mail.ru) яки техник сәркатип өлкән укытучы Н.Ф.Фәхретдинов (Nail.Fahrutdinov@ksu.ru) исеменә җибәрергә.

Конференциянең оештыру комитеты